Республика Татарстан
КАВЗИЯКОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул.Советская, д.66 в,
с.Кавзияково
Телефон: (85559) 4-47-16

Татарстан Республикасы
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЭУЖИЯК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
Совет урамы, 66 в йорт,
Кэужияк авылы, 423360.
Телефон: 4-47-16

ОКПО 93068344 ОГРН 1061687002992 ИНН/КПП 1636005503/163601001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«27» апрель 2018 ел №4

## "Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү кагыйдәләрен раслау турында"

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында 25.06.2013 елдагы 50-ТРЗ номерлы Кодексы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасының Контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары, Сарман МР Советының 2018 елның 4 апрелендәге 115 номерлы карары "Сарман муниципаль районы муниципаль берәмлекләре башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, Сарман муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисләренең хезмәт өчен түләүнең иң чик күләмнәрен раслау турында»,

Кәүҗияк авыл җирлеге Советы карары:

1. 1 нче кушымта нигезендә Сарман муниципаль районы «Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү турындагы нигезләмәне расларга.
2. 2 нче кушымта нигезендә пенсиягә чыгу сәбәпле, «Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең сайланулы вазыйфаи затына бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне түләү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.
3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында"(PRAVO.TATARSTAN.RU), Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кәүҗияк авыл җирлеге
Советы рәисе Ф.А.Хөснетдинов